Каюмов, Р. Эталон кебек шагыйрь иде / Р. Каюмов: [Чаллы үзәк китапханәсендә Нияз Акмалның 70 еллыгы уңаеннан әдәби чара узды] // Шәһри Чаллы. – 2024. – №16 (6 март). – Б. 7.



# Эталон кебек талантлы шагыйрь иде

Хәтер

Рифат **Каюмов**

**Чаллыда шагыйрь, журналист, Саҗидә Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты Нияз Акмалны искә алдылар.**

Нияз Акмалның тууына 70 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль чара Чаллы үзәк китапханәсендә оештырылды. Анда Татарстан Язучылар берлеге рәисенең беренче урынбасары, шагыйрә Илсөяр Иксанова, «Мәдәни җомга» газетасы баш мөхәррире, язучы Вахит Имамов, «Безнең мирас» журналы баш мөхәррире, шагыйрь Ләбиб Лерон, «Казан утлары» журналы баш мөхәррире, язучы Рөстәм Галиуллин, шагыйрь Газинур Морат, ТР Язучылар берлегенең Чаллы бүлекчәсе җитәкчесе, язучы, шагыйрь Факил Сафин, Нияз Акмал шигырьләренә көйләр язган композиторлар Айдар Тимербаев, Вәсим Әхмәтшин, Риф Гатауллин, Чаллыда яшәп иҗат итүче җырчылар Гөлдания Хәйруллина, Асия Әхмәтшина, Нияз Хаматшин, Сарман районыннан якташлары – Рәйхана Мирсәетова җитәкчелегендәге «Сарман таңнары» әдәби-иҗат берләшмәсе әгъзалары һәм туганнары катнашты.

Кичәне **Илсөяр Иксанова** ачып җибәрде. «Татарстан Язучылар берлегендә әгъза булып торган бик күп язучылар Нияз Акмал белән аралашып яшәде. Хәзер инде яшь буын килә. Алар Нияз Акмалның әсәрләрен укып үсте, аның шигърияте белән тәрбияләнде», – диде ул.

Илсөяр Иксанова, үзенең иҗади биографиясендә Нияз Акмалның зур роль уйнаганын әйтеп, язучы белән танышу тарихын сөйләде. «1977 елда ул мине Лаеш районының Татар Сараланы авылы мәктәбеннән эзләп табып, иҗат канатлары куйды. Ул вакытта Нияз Акмал «Яшь ленинчы» газетасында эшли иде. Шул очрашудан соң без аралашып тордык, редакциягә килеп, яраткан шагыйрьләрем белән таныштым. Алар мине әдәбият дөньясына алып керде. Моның өчен мин Нияз абыйга чиксез рәхмәтле», – диде Илсөяр Иксанова.

**Ләбиб Лерон** да Нияз Акмал турында җылы хатирәләре белән уртаклашты: «Нияз абый – йөрәге белән тоеп иҗат иткән шагыйрьләр рәтеннән. Ул – милләт язмышы, халыкның үткәне һәм киләчәге өчен борчылып яшәгән шагыйрь. Күпкырлы шәхес иде. Беренче чиратта, мин аны яхшы журналист буларак таныйм. Заманында «Яшь ленинчы»да беренче практиканы аңарда үткән идем», – дип искә алды.

**Вахит Имамов** белән Нияз Акмал – яшьтәшләр. Язучы аның белән бергә эшләгән чорны хәтерендә яңартты. «Без университетта укыганда ук таныштык. Балык Бистәсе районы газетасында берничә ай бергә эшләргә насыйп булды. Анда без шагыйрь Кадыйр Сибгатуллинның (1942-1994) шәкертләре булуыбыз белән бәхетле идек. Ни үкенеч, Кадыйр Сибгатуллин – 52, Нияз Акмал 53 яшендә китеп барды. Алар эталон булырдай талантлы шагыйрьләр иде. Аларның яшьли китүе әдәбият өчен зур югалту булды», – дип сөйләде Вахит Имамов.

Нияз Акмалның бертуган апасы **Энҗе Акмалова** энесенең исемен Сарманның берәр урамына бирү турында хыяллануын әйтте. «Энемнең тууына 65 ел тулуга багышланган кичәдә Сарманның берәр урамына Нияз Акмал исемен бирү мәсьәләсе күтәрелгән иде. Ләкин бу эш гел кичектерелеп килде. Туган ягындагы урамнарның берсе шагыйрь исемен йөртсен иде», – диде Энҗе Акмалова.

Ул Нияз Акмалның җәмәгатьчелек тарафыннан даими искә алынуына, аны онытмауларына сөенүен белдерде. Алар гаиләдә биш бала үскәннәр. «Арабызда Нияз гына юк. Энем бик талантлы кеше иде. Данлыклы фамилиядә каласы килеп, кияүгә чыкканда да алыштырмадым», – диде Энҗе ханым.




Р.Каюмов фотосы

**Белешмә**

Шагыйрь, прозаик, журналист Нияз Акмал (1954-2007) – тумышы белән Сарман районы Каташ-Каран авылыннан. Матбугатта беренче шигырьләре мәктәп елларында ук дөнья күрә. Ул Казан дәүләт университетының журналистика факультетында белем ала. «Казан утлары», «Татарстан хәбәрләре», «Мәдәни җомга» һ.б. матбугат чараларында эшли. Татар әдәбиятын үстерү, әдәби мирасны халыкка җиткерүдә зур өлеш кертә. Шигырьләре һәм проза әсәрләре тупланган дистәгә якын китабы басыла.